ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Китапханәләр һәм китапханә эше турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 3 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Китапханәләр һәм китапханә эше турында” 1998 елның 21 октябрендәге 1818 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 1 – 2; 2004, № 2 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 3; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның икенче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“федераль законнар нигезендә “Милли электрон китапханә” федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – Милли электрон китапханә) файдалану мөмкинлеген бирү юлы белән.”;

2) $15^1$ статьяда:

а) өченче өлештә “теркәлергә тиеш” сүзләрен “теркәлү юлы белән дәүләт исәбенә алынырга тиеш” сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Документларны китап ядкарьләренә кертү тәртибе, китап ядкарьләрен китап ядкарьләре реестрында теркәү тәртибе һәм китап ядкарьләре реестрын алып бару тәртибе федераль башкарма хакимиятнең мәдәният өлкәсендәге органы тарафыннан раслана торган китап ядкарьләре реестры турындагы нигезләмә белән билгеләнә.”;

3) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“17 статья. **Китапханә хезмәте күрсәтүне координацияләүне һәм кооперацияләүне тәэмин итүдә дәүләтнең катнашуы**

Фондлардан нәтиҗәле файдалану максатларында һәм китапханәләрдән файдаланучыларның мәгълүматка ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү өчен дәүләт аларның ресурсларыннан бергәләшеп файдалануны кызыксындыра, гомуми

файдаланудагы дәүләт китапханәләренең аларның ресурсларыннан (китапханәара абонементтан, җыелма каталоглардан, автоматлаштырылган мәгълүмат базаларыннан, депозитарийлардан) бергәләшеп файдалану өчен шартлар тудыру эшчәнлеген финанслый, шулай ук федераль законнар нигезендә Милли электрон китапханәдән файдаланучыларның Милли электрон китапханә объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итә.";

4) 25 статьяның беренче өлешендә "законнар нигезендә махсус лотереяләр, аукционнар уздырудан, башка коммерция гамәлләреннән алына торган табышлар" сүзләрен "законда тыелмаган башка кертемнәр" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 17 ноябре
№ 83-ТРЗ